**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**
**_____________ И.Г.Һадиуллин**
**«19» ноябрь 2025 нче ел**

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең татар укучылары өчен 2026 нчы елда туган (татар) әдәбияттан дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татар әдәбиятыннан әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба - Кодификатор) – 2026 нчы елгы дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенә контроль бәяләү материаллары төзү өчен дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенең КБМ эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификаторда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, үрнәк белем бирү программасына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

Бу документ татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшен төзү өчен нигез булып тора, шуңа да уку материалын гомумиләштерү һәм системалаштыру принципларыннан гыйбарәт.

## I БҮЛЕК. Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган теоретик база һәм әсәрләр исемлеге

*1 нче таблица*

| Бүлек коды | Контроль бәяләү материалының коды | Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| ***1*** | ***Әдәбият теориясеннән һәм матур әдәбият әсәрләреннән белешмә*** | |
| | 1.1 | Фольклор. Фольклор жанрлары. |
| | 1.2 | Әдәби образ. |
| | 1.3 | Эчтәлек һәм форма. |
| | 1.4 | Әдәби төрләр: проза (эпик төр), лирика, драма; төрара формалардан лиро-эпика. Әдәби жанрлар: хикәя, повесть, роман; лирик шигырь, хикмәт; поэма, баллада, мәсәл; комедия, трагедия, драма. |
| | 1.5 | Тема. Проблема. Идея. Автор позициясе. Конфликт. Сюжет һәм сюжет элементлары: экспозиция, төенләнеш, кульминация, чишелеш, эпилог. Сюжеттан тыш элементлар. Композиция. Образлар системасы. Образларның төрләре. Персонаж. Характер. Тип. Автор образы. Лирик герой. Пафос. Сурәтләнгән дөнья (портрет, пейзаж). |
| | 1.6 | Әдәби әсәрнең теле. Әдәби әсәрдә тел-сурәтләү чаралары: лексик чаралар (синоним, омоним, антоним, фразеологизм һ.б.), стилистик чаралар (инверсия, кабатлау, антитеза һ.б.), троплар (чагыштыру, метафора, метонимия, аллегория, эпитет, сынландыру һ.б.). |
| ***2*** | ***Әдәби әсәрләрдән*** | |
| | 2.1 | К.Насыйри.<br>“Әбүгалисина” повесте. |
| | 2.2 | М.Акъегет.<br>“Хисаметдин менла” әсәре. |
| | 2.3 | Г.Тукай.<br>“Шүрәле”, “Милли моңнар”, “Туган авыл”, “Ана догасы”, “Җәйге таң хатирәсе” шигырьләре, “Исемдә калганнар” автобиографик повесте. |
| | 2.4 | М.Гафури.<br>“Урман”, “Ана”, “Ана теле” шигырьләре, “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле. |
| | 2.5 | С.Рәмиев. |

| Бүлек коды | Контроль бәяләү материалының коды | Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| | | “Авыл”, “Таң вакыты” шигырьләре. |
| | 2.6 | Г.Ибраһимов.<br>“Яз башы”, “Табигать балалары”, “Алмачуар” хикәяләре. |
| | 2.7 | Ф.Әмирхан.<br>“Хәят” повесте (өзекләр). |
| | 2.8 | Г.Исхакый.<br>“Кәҗүл читек” хикәясе, “Җан Баевич” комедиясе. |
| | 2.9 | Г.Камал.<br>“Беренче театр” комедиясе. |
| | 2.10 | М.Фәйзи.<br>“Галиябану” драмасы. |
| | 2.11 | Ш.Камал.<br>“Буранда” хикәясе. |
| | 2.12 | Һ.Такташ.<br>“Ак чәчәкләр” шигыре, “Мокамай”, “Алсу” поэмалары. |
| | 2.13 | Г.Кутуй.<br>“Сагыну” нәсере. |
| | 2.14 | М.Җәлил.<br>“Имән”, “Кошчык”, “Чулпанга”, “Җырларым”, “Кызыл ромашка”, “Чәчәкләр”, “Вәхшәт” шигырьләре, “Сандугач һәм чишмә” балладасы. |
| | 2.15 | Ф.Кәрим.<br>“Кыр казы”, “Ватаным өчен”, “Сөйләр сүзләр...”, “Бездә яздыр” шигырьләре. |
| | 2.16 | Х.Туфан.<br>“Каеннар сары иде”, “Кайсыгызның кулы җылы?” шигырьләре. |
| | 2.17 | С.Хәким.<br>“Колын”, “Бу кырлар, бу үзәннәрдә”, “Башка берни дә кирәкми”, “Җырларымда телим” шигырьләре. |
| | 2.18 | Г.Бәширов.<br>“Туган ягым – яшел бишек” автобиографик повесте (өзекләр). |
| | 2.19 | Ф.Хөсни.<br>“Йөзек кашы” повесте. |
| | 2.20 | Ә.Еники.<br>“Кем җырлады?”, “Әйтелмәгән васыять”, “Матурлык” хикәяләре. |
| | 2.21 | Ш.Хөсәенов.<br>“Әниемнең ак күлмәге” драмасы. |
| | 2.22 | А.Гыйләҗев.<br>“Җомга көн, кич белән...”, “Өч аршын җир” повестьлары (өзекләр). |
| | 2.23 | Т.Миңнуллин.<br>“Әлдермештән Әлмәндәр” әсәре. |
| | 2.24 | М.Мәһдиев.<br>“Без – кырык беренче ел балалары”, “Кеше китә – җыры кала” повестьлары. |
| | 2.25 | Ф.Яруллин. “Җилкәннәр җилдә сынала” повесте, “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”, “Җыр калдырыйк” шигырьләре, “Кояштагы тап” әкияте. |
| | 2.26 | Р.Мөхәммәдиев.<br>“Беренче умырзая” әсәре. |

| **Бүлек коды** | **Контроль бәяләү материалының коды** | **Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге** |
|---|---|---|
| | 2.27 | Г.Афзал.<br>“Мыек борам”, “Йөз кабат”, “Өф-өф итеп” шигырьләре. |
| | 2.28 | Р.Харис.<br>“Кеше кайчан матур була”, “Туган җирем” шигырьләре. |
| | 2.29 | Р.Фәйзуллин.<br>“Минем телем”, “Якты моң”, “...Җыя кеше” шигырьләре |
| | 2.30 | М.Галиев.<br>“Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре. |
| | 2.31 | М.Әгъләмов.<br>“Каеннар илендә”, “Матурлык минем белән” шигырьләре. |
| | 2.32 | Р.Миңнуллин.<br>“Туган телемә”, “Һәйкәлләрне тыңлыйк!” шигырьләре. |

## II БҮЛЕК. Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге

*2 нче таблица*

| **Таләпнең коды** | **Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр** |
|---|---|
| **1.** ***Белергә / аңларга*** | |
| 1.1 | Тәкъдим ителгән әсәрләрнең эчтәлеген һәм әсәргә анализ ясау юлларын. |
| 1.2 | Тәкъдим ителгән авторларның тормыш һәм иҗат биографиясен. |
| 1.3 | Төп теоретик төшенчәләрне. |
| **2.** ***Эшли белергә*** | |
| 2.1. | Әсәрнең эчтәлеген аңлата белергә. |
| 2.2. | Әдәби әсәрне анализлый белергә: әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып алырга, әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгеләргә, геройга характеристика бирергә, әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын билгеләргә. |
| 2.3. | Әдәби текстка төр һәм жанр үзенчәлекләреннән чыгып анализ ясый белергә, геройларга характеристика бирә белергә. |
| 2.4. | Әдәби әсәрләрне чагыштыра белергә. |
| 2.5. | Әсәрдә автор позициясен, автор стиленең үзенчәлеген, кулланылган тел-сурәтләү чараларының төрләрен, функцияләрен, әдәби алымнарны билгели алырга. |
| 2.6. | Үз мөнәсәбәтен нигезле итеп дәлилли алырга. |
| 2.7. | Укылган әсәргә карата үз мөнәсәбәтен язма формада бирә алырга. |
| **3.** | ***Алган белем һәм күнекмәләрне гамәли эштә һәм көндәлек тормышта куллану*** |
| 3.1. | Татар теленең әдәби нормаларына таянып, эзлекле текст язарга. |
| 3.2. | Әңгәмә һәм бәхәсләрдә катнашырга. |